| | | |
|---|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br><br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br><br>**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

«14» декабрь **2023г.** **№** 188

Теләче муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 9 декабрендәге 545 номерлы карары белән расланган «2021-2025 елларга Теләче муниципаль районы халкын наркотиклаштыруны профилактикалау» муниципаль программасына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2006 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 9 декабрендәге 545 номерлы карары (13.12.2022 ел № 270 карар редакциясендә) белән расланган «2021-2025 елларга Теләче муниципаль районы халкын наркотиклаштыруны профилактикалау» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Муниципаль программа атамасын «2021-2025 елларга Теләче муниципаль районы халкын наркотиклаштыруны профилактикалау», түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «2021-2026 елларга Теләче муниципаль районы халкын наркотиклаштыруны профилактикалау».

1.2. Программа паспортындагы программаның структурасын түбәндәге тәртиптә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программа атамасы | «2021-2026 елларга Теләче муниципаль районы халкын наркотиклаштыруны профилактикалау (алга таба - Программа) муниципаль программасы |

1.3. Программа паспортында Программаны гамәлгә ашыру сроклары юлын түбәндәге тәртиптә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаны тормышка ашыру сроклары | Программаны гамәлгә ашыру 2021-2026 еллар дәвамында башкарылачак |

1.4. Программа паспортында программаны төгәл финанслау юлын түбәндәге тәртиптә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Программаны финанслау | Билгеләнгән тәртиптә бүленеп бирелә торган күләмнәрдә Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле бюджеты акчалары.<br>Күздә тотылган җирле бюджет акчаларын җәлеп итү, бюджеттан тыш чыганаклар.<br>Программаны финанслау күләме тәшкил итәчәк:<br>- 2021 елда - 6,5 мең сум;<br>- 2022 елда - 6,5 мең сум;<br>- 2023 елда - 6,5 мең сум;<br>- 2024 елда - 6,5 мең сум;<br>- 2025 елда - 6,5 мең сум;<br>- 2026 елда - 6,5 мең сум.<br>Программаны финанслау күләме тиешле елга һәм план чорына бюджет проектын формалаштырганда ел саен ачыкланырга тиеш.<br>Федераль, республика бюджеты һәм бюджеттан тыш чыганаклардан акчалар күләме ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк |

1.5. «2021-2026 елларга Теләче муниципаль районы халкын наркотиклаштыруны профилактикалау» программасы чараларын кушымта нигезендә бәян итәргә.

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«14» 12 2023 № 188
карарына кушымта

**Муниципаль Программа чаралары**
**«2021-2026 елларга Теләче муниципаль районы халкын наркотиклаштыруны профилактикалау»**

| Төп чаралар атамасы | Башкаручылар | Төп чараларны башкару вакыты | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикатор күрсәткечләре | | | | | | | Финанслау, мең сум (ел саен) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 2020 ел (база елы) | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел | 2025 ел | 2026 ел | |
| **Максат: Теләче муниципаль районында наркотикларны законсыз тарату һәм наркотиклар куллануның масштабларын киметү** | | | | | | | | | | | |
| **1 бурыч. Наркотикларның законсыз әйләнешенә каршы көрәш буенча хокук саклау органнарының көчләрен арттыру** | | | | | | | | | | | |
| 1.1. Наркотик чараларның һәм психотроп матдәләрнең законсыз әйләнеше белән бәйле җинаятьләрне ачыклауга, булдырмый калуга һәм ачуга юнәлдерелгән оператив-эзләү чаралары үткәрергә | Россия Эчке эшләр министрлыгының Теләче районы буенча бүлеге (килешү буенча) | 2021-2026 еллар. | Тикшерелгән авыр һәм аеруча авыр наркоҗинаятьләрнең саны арту, процентларда | 100 | 100,1 | 100,2 | 100,3 | 100,3 | 100,3 | 100,3 | - |
| 1.2. Наркотикларның яңа төрләре, шулай ук контрольсез куллану өчен файдаланыла торган контрольсез психоактив чаралар һәм матдәләр әйләнешен чикләү эшчәнлеген | Россия Эчке эшләр министрлыгының Теләче районы буенча бүлеге | 2021-2026 еллар. | Ачыкланган очраклар саны | | | | | | | | - |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| гамәлгә ашыру; "Интернет" челтәрендә наркотиклар турында мәгълүмат тарату һәм наркотикларны пропагандалау буенча иҗтимагый контроль оештыру | (килешү буенча), Саба һәм Теләче районнары буенча Роспотребнадзор (килешү буенча) | | | | | | | | | | |
| 1.3. Кыргый үскән һәм үстерелә торган наркотиклы үсемлекләр үсү урыннарын ачыклау һәм бетерү буенча оператив-профилактик чаралар комплексын тормышка ашыру | Россия Эчке эшләр министрлыгының Теләче районы буенча бүлеге (килешү буенча), АҖ башлыклары (килешү буенча) | 2021-2026 еллар. | Наркотиклы үсемлекләр үсешенең ачыкланган учаклары саны арту | 3 | 4 | 5 | 6 | 6 | 6 | 6 | - |
| 1.4. "Интернет" челтәре мөмкинлекләрен киңрәк кулланып гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү буенча кабул ителгән ышаныч телефоны эшенең һәркем файдалана алырлык һәм нәтиҗәлелеген күтәрергә | Россия Эчке эшләр министрлыгының Теләче районы буенча бүлеге (килешү буенча), АҖ башлыклары (килешү буенча) | 2021-2026 еллар. | Телефон аша килгән мөрәҗәгатьләр саны | | | | | | | | - |
| **2 бурыч. Халык арасында сәламәт яшәү рәвеше алып баруга уңай һәм наркотиклар куллануга тискәре мөнәсәбәт урнаштыруны формалаштыру** | | | | | | | | | | | |
| 2.1. Белем бирү учреждениеләрендә | МКУ «Мәгариф | 2021-2026 еллар | Елына чаралар саны, берәмлекләр | 8 | 10 | 12 | 14 | 14 | 14 | 14 | - |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| профилактик эш оештырырга, шул исәптән: Республикакүләм антинаркотик акцияләр: «Сообщи, где торгуют смертью!», «Жизнь без наркотиков», «Будь готов! Скажи, нет!», «Россия без табака» | бүлеге» | | | | | | | | | | |
| | ЯЭСҺТБ | | | | | | | | | | - |
| | «Олимп» яшьләр үзәге | | | | | | | | | | 3,5 |
| | МБУ «ФОРПОСТ» | | | | | | | | | | 3 |
| 2.2. Балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе белән үзара хезмәттәшлекне оештырырга | Районның наркотикларга каршы комиссиясе | 2021-2026 еллар | Бер елга уртак утырышлар саны, берәмлекләр | 1 | 2 | 3 | 4 | 4 | 4 | 4 | - |
| 2.3. Авыр тормыш хәлендә калган балалар һәм яшүсмерләр белән эш алып бару, шул исәптән профилактик проектларны тормышка ашыру аша да | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф оешмалары | 2021-2026 еллар | Елына чаралар саны, берәмлекләр | 14 | 14 | 14 | 14 | 14 | 14 | 14 | - |
| 2.4. Мәгариф учреждениеләрендә укучыларның ата-аналары белән наркотикларга каршы профилактик эш алып барырга ("Уңышка юл") | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф оешмалары | 2021-2026 еллар | Елына чаралар саны, берәмлекләр | 14 | 14 | 14 | 14 | 14 | 14 | 14 | - |
| 2.5. Наркотик һәм психотроп матдәләрне кулланучыларны иртә ачыклау системасын үстерергә, шул исәптән гомуми белем бирү мәктәпләре укучыларына һөнәри тикшерүләр үткәрергә. | МКУ «Мәгариф бүлеге», мәгариф оешмалары | 2021-2026 еллар | Һөнәри тикшерүләр белән шөгыльләнүче укучылар саны, кеше. | - | 300 | 300 | 300 | 300 | 300 | 300 | - |
| 2.6. Халыкка наркологик ярдәм күрсәтүче сәламәтлек саклау учреждениеләре өчен | ДАССУ «Теләче РҮХ» | 2021-2026 еллар | Экспресс-тестлар, берәмлек сатып алу санын арттыру | 130 | 150 | 150 | 150 | 150 | 150 | 150 | Муниципаль учрежден |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| наркотикларны ачыклау, дәвалау һәм реабилитацияләү өчен медицина аппаратурасы сатып алу | | | | | | | | | | | иеләрне финанслау лимитлары кысаларында |
| 2.7. Наркотикларга бәйле кешеләргә социаль-психологик ярдәм күрсәтү, шул исәптән аларда дәвалауга мотивация формалаштыру | "Теләче үзәк район хастаханәсе" ДАССУ | 2021-2026 еллар | Наркотикларга бәйле кешеләргә социаль-психологик ярдәм күрсәтү | | | | | | | | - |
| 2.8. Яшьләрнең массакүләм ял итү урыннарында наркотикларга каршы эш | ЯЭСһТБ | 2021-2026 еллар | Елына чаралар саны, берәмлекләр | 1 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | Муниципаль учреждениеләрне финанслау лимитлары кысаларында |
| 2.9. Сәламәт яшәү рәвешен популярлаштыруга һәм психоактив матдәләр куллануны кисәтүгә юнәлдерелгән җәмәгатьчелек фикерен формалаштыру буенча массакүләм мәгълүмат чаралары эшен дәвам итәргә | "Татмедиа" ААҖ филиалы (килешү буенча) | 2021-2026 еллар | Бер ел эчендә публикацияләр саны, берәмлекләр | 82 | 85 | 87 | 90 | 90 | 90 | 90 | - |
| **3 бурыч. Физик культура һәм спорт мәнфәгатьләре буенча түгәрәкләрдә балаларны һәм яшьләрне системалы дәресләргә җәлеп итү өчен шартлар тудыру, волонтерлык хәрәкәтен үстерү** | | | | | | | | | | | |
| 3.1. Балаларда һәм яшүсмерләрдә шәхси, рухи һәм әхлакый кыйммәтләрне аңлауны стимуллаштыруга юнәлдерелгән методикаларны кертергә | МКУ «Мәгариф бүлеге» | 2021-2026 еллар | «Самостоятельные дети» проектында катнашкан балалар һәм яшүсмерләр саны | 58 | 58 | 60 | 65 | 65 | 65 | 65 | - |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ("Мөстәкыйль балалар" проектын гамәлгә ашыру) | | | | | | | | | | | |
| 3.2. Халыкның барлык категорияләре арасында массакүләм физкультура-спорт ярышлары уздыру:<br>- кышкы Спартакиада;<br>- Спорт һәм сәламәтлек декадасы;<br>- Чаңгычы көне;<br>- көзге кросс;<br>- май чабышы;<br>- җәйге Спартакиада | ЯЭСһТБ | 2021-2026 еллар | Халык саны, кеше | 198 | 210 | 215 | 220 | 220 | 220 | 220 | Муниципаль учреждениеләрне финанслау лимитлары кысаларында |
| 3.3. Балалар һәм яшүсмерләрне «Теләче» спорт мәктәбе, «Юность» спорт мәктәбе һәм балалар сәламәтләндерү-белем бирү үзәге спорт түгәрәкләренә һәм секцияләренә җәлеп итү буенча мәгълүмати-аңлату эшләре алып бару | «Теләче» СМ, «Юность» СМ, БСМҮ | 2021-2026 еллар | Елга мәгълүмати-аңлату чаралары саны, берәмлекләр | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 | 3 | - |
| 3.4. Халыкны наркотиклаштыруны профилактикалау проблемалары буенча конференцияләр, "түгәрәк өстәлләр" утырышлары, семинарлар оештыру | ЯЭСһТБ, МКУ "Мәгариф бүлеге" | 2021-2026 еллар | Елына чаралар саны, берәмлекләр | 1 | 1 | 2 | 3 | 3 | 3 | 3 | Муниципаль учреждениеләрне финанслау лимитлары кысаларында |
| **4 бурыч. Наркотикларга каршы эшчәнлекне оештыруны, аны норматив-хокукый һәм методик яктан тәэмин итүне камилләштерү** | | | | | | | | | | | |
| 4.1. Районда наркоситуация мониторингын алып баруны оештырырга | Наркотикларга каршы комиссия | 2021-2026 еллар | Наркотикларга каршы комиссия утырышлары саны | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | 4 | - |
| 4.2. Яшьләр сәясәте белгечләре | ЯЭСһТБ, | 2021-2026 | Квалификация күтәрү | 0 | 1 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | - |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| өчен наркотикларга каршы һәм профилактик эш буенча квалификация күтәрү курсларында катнашу | МБУ «Олимп» яшьләр үзәге, МБУ «ФОРПОСТ», МКУ «Мәгариф бүлеге» | еллар (билгеләнеше буенча) | курслары узучылар саны | | | | | | | | |
| 4.3. Район яшьләре арасында социологик тикшеренүләр үткәрүне оештырырга | ЯЭСhТБ, МБУ «Олимп» ЯҮ, МБУ «ФОРПОСТ» | 2021-2026 еллар | Елына чаралар саны, берәмлекләр | 1 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | 2 | - |
| 4.4. Җирле Интернет-ресурсларда наркотикларга каршы юнәлешле мәгълүмат бастырып чыгару | МБУ «ФОРПОСТ» | 2021-2026 еллар | Елга публикацияләр саны, берәмлекләр | 4 | 6 | 7 | 8 | 8 | 8 | 8 | - |
| 4.5. Район китапханәсенең наркотикларга каршы әдәбият белән җиһазландыру һәм аларда тематик күргәзмәләр оештыру | Мәдәният бүлеге | 2021-2026 еллар | Елына китап күргәзмәләре саны, берәмлек | 16 | 18 | 20 | 22 | 22 | 22 | 22 | Муниципаль учреждениеләрне финанслауга лимитлар кысаларында |
| 4.6. Наркоманияне профилактикалау буенча методик әдәбият һәм күрсәтмә агитация чараларын эшләү, бастырып чыгару һәм тарату | Мәдәният бүлеге | 2021-2026 еллар | Тарату материаллары, берәмлекләр саны | 50 | 70 | 80 | 90 | 90 | 90 | 90 | Муниципаль учреждениеләрне финанслау лимитлары кысаларында |
| | | | | | | | | | | **Барлыгы:** | **6,5** |